1679-02
3486

К. ИВАНОВ



# НЯР[illegible]

1679-02

МӘКТӘП СЕРИЯСЕ

Константин Иванов

# НАРСПИ

ПОЭМА

*Чуваш теленнән*
*Шәрәф Мөдәррис тәрҗемәсе*
*Н. Карпов рәсемнәре.*

ТАТГОСИЗДАТ
МАТУР ӘДӘБИЯТ СЕКТОРЫ
КАЗАН 1941

Инв. № 3486

ЧУВАШСКАЯ
КНИЖНАЯ ПАЛАТА
г. Чебоксары Чувашской АССР

## ЧУВАШ ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК ШАГЫЙРЕ

Укучыларга тәкъдим ителгән шушы „Нарспи“ поэмасының авторы Константин Васильевич Иванов, хәзерге Башкортстан республикасы, Бишбүләк районы, Слагпуж (Слагбаш) авылында бай тормышлы крестьян семьясында 1890 нчы елның 2 нче июнендә (яңа стиль белән) туа. Шагыйрьнең ата-анасы бирегә Чебоксарның бер уездыннан бәхет эзләп күчеп килгән булалар.

К. В. Иванов башта авыл мәктәбендә укый. Аннан соң Бәләбәй шәһәрендә белем ала. Бәләбәй шәһәрендә бер ел укыганнан соң Сембер (Ульяновск) шәһәрендәге Чуваш укытучылык мәктәбенең хәзерлек курсына керә. Биредә ул бик тырышып укый. Әдәбият белән кызыксына башлый. Европа һәм рус әдәбияты классикларыннан Шекспир, Гете, Һейнә, Шиллер, А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов, А. В. Кольцов, Н. А. Некрасов, Л. Н. Толстой, В. Г. Белинский әсәрләрен зур кызыксыну һәм тирәнтен ярату белән укый, өйрәнә.

Ивановның укый торган мәктәбе патша Россиясендә чувашлар өчен бердәнбер укытучылык мәктәбе була. Бу мәктәп коточкыч авыр шартларда эш алып бара. Ул шушы мәктәпнең инспекторы И. Я. Яковлевның тырышлыгы белән генә үзенең яшәвен дәвам иттереп килә.

1905 нче елгы революция дулкыннары Сембердәге Чуваш укытучылык мәктәбенә дә килеп керәләр. Революция бу мәктәпнең укучыларына да бик нык йогынты

ясый. Ярым ач, ярым ялангач, коточкыч авыр шартларда яшәүче укучылар 1906 нчы елның ноябрь аенда „бунт“ оештыралар һәм үзләренең материаль көнкүреш шартларын яхшырту, уку-укыту эшләрен ныклы бер тәртипкә салу һәм башка шундый таләпләрен җирле властьларга белдерәләр. Иреклек өчен янучы һәм бу юлда ныклы көрәш алып баручы К. В. Иванов бу хәрәкәткә иң беренче булып, актив рәвештә кушыла һәм үзенең иптәшләрен дә көрәшкә рухландыра.

1907 нче елның февралендә, II нче Дәүләт думасы ачылу көнендә мәктәп укучылары арасында революцион дулкын тагын да көчәя. Мәктәп түбәсендә кызыл байрак җилферди.

Революция төшүгә таба барганда кара реакциянең кабахәт ялчылары мәктәпне таркатырга, революцион рух белән сугарылган укучыларны эзәрлекләргә керешәләр. Ләкин Яковлевның тырышлыгы аркасында гына мәктәп ябылмый кала. Забастовкага катнашуда гаепләнгән К. В. Иванов мәктәптән чыгарып ташлана һәм политик тотнаксызлыкта гаепләнгән тагын 40 лап укучы укудан куыла. И. Я. Яковлев Ивановның искиткеч талантлы икәнен белә һәм күп тырышканнан соң аны яңадан мәктәпкә алдыруга ирешә. Шагыйрь мәктәпне тәмамлау белән тагын да кыенрак хәлләргә очрый. Ул эш эзләп авылдан-авылга йөри. Ләкин эш таба алмый. Яковлев монда да аңа ярдәмгә килә. Ивановны үз мәктәбенә эшкә урнаштыра. Шагыйрь бу вакытта үзенең бөтен көчен, энергиясен әдәбиятка, поэзиягә бирә. Ул шигырьләр, поэмалар, әкиятләр, легендалар яза. Лермонтов, Кольцов, Некрасов, аеруча Горький Ивановка зур йогынты ясыйлар.

Ивановның әдәби эшенең башлангыч вакыты 1905 нче елгы революциядән соң булган кара реакция елларына туры килә.

1907 — 1908 нче елларда Россиядә кара реакция канат җәя. Кара реакция һәртөрле прогрессив омтылышларга ату-кисү, дарга асу белән җавап бирә. Менә бу вакытта, кайбер интеллигент катлаулар арасында пессимизм, төшенкелек һәм революция көченә ышанмаучылык тарала башлый. Буржуаз матбугат идеалистик философияне, мистицизмны, индивидуальлекне яклап чыгыш ясый. Бу вакытта тик кайбер язучылар гына чын тормышны раслый торган, кеше образын реаль рәвештә

күрсәткән әсәрләр язалар. Мондый язучылар арасында чуваш халкының бөек шагыйре Иванов та була. Ул:

Шушы якты дөньяда
Юктыр адәмнән көчле,
Җирдә, суда — һәркайда
Йөри ул хуҗа төсле

ди. Һәм моны үзенең гүзәл әсәрләрендә раслый.

Шагыйрь Иванов тулы цикл шигъри әкиятләр, лирик шигырьләр яза. Кольцов һәм Һейнәнең күп кенә шигырьләрен, шулай ук Лермонтовның „Купец Калашников хакында җыр“ исемле поэмасын һәм байтак кына шигырьләрен бик гүзәл итеп чуваш теленә тәрҗемә итә. Шулай ук чуваш әдәбиятында классик поэма булган „Нарспи“ны яза. Бу поэма чуваш әдәбияты өчен генә түгел, бәлки гомумән безнең совет әдәбияты өчен зур хәзинә булып тора. Ләкин ул чорда чуваш телендә оригиналь әсәрләр бастыру бөтенләй мөмкин булмый. Чөнки патша цензурасы моңа рөхсәт итми. Ул вакытта бары тик беркадәр фольклор материалларны гына бастырырга мөмкин була. Шагыйрь үзе исән вакытта, „Ике кыз“, „Тол хатын“, „Тимер ватыгы“ дигән шигырьләрен һәм төп поэтик хезмәте булган „Нарспи“ поэмасын „Чуваш халык әкиятләре“ дигән исем астында, исемсез-фамилиясез генә чыгара ала. Шулар өстенә ул, „Ачлыкка аптыраганнар“ дигән әсәрен яза, һәм „Шәйтан қолы“ дигән трагедия эшли башлый.

Иванов туктаусыз эшли. Начар шартларда яши. Авыр эш аның сәламәтлеген какшата. Аңа үпкә авыруы эләгә. Шагыйрь бу авырудан терелә алмый һәм бөек социалистик революцияне һәм үзенең сөйгән халкының мәңгелеккә азат булуын күрү бәхетенә ирешми. Ул 1915 нче елның 8 нче апрелендә (яңа стиль белән) 25 нче яшендә үлә.

„Нарспи“ поэмасы Ивановның иң зур һәм иң яхшы әсәре. Бу поэма чуваш халкының тирән мәхәббәтен яулап ала. Поэма искиткеч популяр булып китә. Чуваш халкы бу поэмада үзенең тормышын, хисләрен, кайгысын-шатлыгын күрә. Шуның өчен дә поэма хәзер дә чуваш халкының тарихи атаклы әсәре булып санала. Аның рус телендә генә дә ике вариантта тәрҗемәсе бар. Шулай ук ул СССР ның башка халыклары

теленә дә тәрҗемә ителә. Шагыйрь революция идеаллары белән ялкынланып, коллыкка, караңгылыкка, акча-капитал властена каршы кыю һәм кискен протест белдерә. Аның бу протесты чуваш халкының тормышын, хатын-кызларның коллыгын күрсәтеп 1908 нче елда язылган „Нарспи“ поэмасында ачык чагыла.

„Нарспи“ поэмасы шуның өчен кыйммәтле, чөнки анда бөтен бер чор һәм чуваш халкының тормышы, хисләре, кайгысы-шатлыгы чагыла. Монда чуваш халкының прогрессив һәм революцион таләбе, коллыкка, акча-капитал властена каршы көрәше гәүдәләнә.

„Нарспи“ поэмасында чуваш хатын-кызларының изелүе, мыскыл ителүе аеруча ачык, көчле образлар аркылы күрсәтелә. Өстен катлауларга, чуваш байларына һәм гомумән патша монархиясенә тирән нәфрәт белдерелә.

Поэмада чуваш яшьләренең бер-берсенә булган тирән мәхәббәте, идеаллары оста сюжетка корылып, матур образларда биреләләр. Ләкин яшьләрнең гадел һәм саф яратулары зур авырлыкларга, киртәләргә очрап, фаҗигале рәвештә тәмам була.

Поэмада күренешләр, вакыйгалар матур тел, тирән тойгы, йөрәккә үтеп керерлек көчле лирик рух белән, онытылмаслык гүзәл романтик алымнар белән сурәтләнәләр.

Михәдәр бай үзенең байлыгы һәм гүзәл кызы белән мактана. Ул үзенең кызын ярата һәм шуның өчен дә аңа бай кияү эзли. Ләкин ул кызның йөрәген аңламый яки аңларга теләми. Шуңа күрә кызның ярлы егет Сәтнәрне яратканын бернигә дә куймый. Нарспины бер карт байга — „карт бүрегә“ сата. Карт бай Тохтаман, Нарспины коточкыч изү һәм мыскыл астында тота. Соңгы чиктә Нарспи үзенең ире — Тохтаманны үтерергә һәм Сәтнәр янына качарга мәҗбүр була. Нарспи үзенең әтисен, аның йөзендә бөтен чуваш изүчеләренең, чуваш милли буржуазиясенең пычрак йөзен кыю рәвештә ачып сала, аларны хурлык һәм нәфрәт белән тамгалый.

Әй эткәем, эткәем,
Яхшы тормыш кайда ул.
Түгел байлык эчендә, —
Җанга якын җанда ул.
. . . . . . . . . .

Үстердегез сез әткәй,
Үстердегез, бактыгыз.
Ләкин үскәч юк булдым,
Акча өчен саттыгыз.

. . . . . . . . . . . . . .

Әткәй, ялгыз кызыңны,
Ник бирдең соң бүрегә.
Сиңа рәхәт булып шул,
Акча гына күренә, — ди.

Нарспи батыр кыз. Шагыйрь Нарспи образында чуваш хатын-кызларының иң алдынгы, иң йөрәкле вәкилен күрсәтә. Нарспи, Сәтнәргә караганда да кыюрак итеп бирелә.

Ивановның „Нарспи“ поэмасы гаять матур һәм кыю әсәр. Монда шагыйрьнең саф талантына, яшьлек романтикасына, художество осталыгына хәйран каласың. Поэма — халыкчыл әсәр. Поэманың теле — саф халык теле. Шуның өчен дә Иванов — чуваш әдәби телен тудыручы, чуваш әдәбиятының беренче карлыгачы булып санала да.

Безнең татар совет әдәбияты өчен Г. Тукай никадәр кыйммәтле һәм хөрмәтле булса — чуваш әдәбияты өчен Иванов та шул кадәр кыйммәтле.

Контрреволюцион чуваш милләтчеләре шагыйрьнең иҗатын төрлечә томалап калдырырга — халыкка күрсәтмәскә, аның әһәмиятен югалтырга тырыштылар. Ләкин алар күп миллионлы халык массаларына каршы бара алмадылар, хурлык һәм нәфрәт белән тамгаландылар.

Чуваш халкы, һәм гомумән совет халкы, К. В. Ивановны укый, аңлый һәм истә тота.

1940 нчы елның октябрендә шагыйрьнең тууына 50 ел тулу көнен бөтен СССР халкы бердәм рәвештә билгеләп үтте. Менә бу — К. В. Ивановның халык өчен никадәр кадерле һәм кирәкле шагыйрь икәнлеген тагын бер кабат раслый.

*С. УРАЙСКИЙ.*



## 1. СИЛБИ АВЫЛЫНДА

Боз[1] аеның ахырында
Кояш карый яктырак,
Силби — чуваш авылында
Карда эри яхшырак.

Таулар, үрләр кап-кара,
Карлар тәмам киткәнгә.
Чыга чирәм ямь-яшел,
Кояш нурын сипкәнгә.

Суык, усал кыш китә,
Китә елап, тавышлап,
Елый бозлы яшь белән,
Үткән көнен сагышлап.

Иңкүлектә, тугайда,
Сулар гөрли, гөр килә.
Ләкин күпме елама —
Кояш нурын гел сибә.

---

[1] Боз ае — чувашлар элек айлар исемен үзләренчә атаганнар Боз ае — март ае вакытына туры килә.

Суык, усал, явыз кыш
Агып китә тугайга.
Елый-елый-елый да,
Агып китә шулай да.

Күктә кояш көлгәндә,
Җирне сулар юганда,
Бала-чага уйнашып,
Чабып йөри урамда.

Килде матур юмарт яз,
Килде шатлык аңкытып,
Кояш нурлый дөньяны
Кыш йокысын айнытып.

Кара урман җанлана,
Яшел төскә каплана.
Япан-буш кыр яшәреп,
Ямьгә чумып, мактана.

Төрле-төрле чәчәкләр
Тәмле исләр бөркидер.
Бар җирдә дә кошларның
Матур җыры гөрлидер.

Күктә, болыт каршында,
Җитез тургай уйныйдыр.
Тигез чирәм өстендә,
Бәрән-сарык утлыйдыр.

Шунда, көтү янында,
Боргы уйный бер бала;
Карыны ачкач карый ул
Силби авылына таба.

Силби авылы — бай авыл,
Тора урман алдында.
Матур, төзек, шәп өйләр
Зифа таллар астында.

Читән — авыл тирәсе,
Яшел чыбык читәне.

Анда да бар, монда да
Узган елның кибәне.

Зур урамда өйләрнең
Башы сары тактадан.
Сул якта да, уңда да
Матур яшел бакчалар.

Йортлар, өйләр, амбарлар
Шундый гүзәл, күр әле!
Матур саргылт капкалар
Челтәр-челтәр түбәле.

Силби авылы — зур авыл,
Әйтерсең лә — бер шәһәр.
Ахыры, монда, чувашта
Мал күп, дисең, шул кадәр.

---

Ага шунда бер елга,
Бу зур авыл читендә.
Кояш бизәк бизәкләп,
Уйный сулар битендә.

Чиста суның астында
Күксу болыт чайкала.
Карт тал суга баш ия,
Үзен күреп шатлана.

Менә күпер, зур күпер,
Болынга елга таша.
Шунда бер карт тын гына
Кармагын суга сала.

Житез-житез сазаннар
Көмеш төслеләр генә...
Шул карт, суалчан белән,
Балыклар алдый менә.

Әнә анда балалар,
Бата-чума чабалар.
Балык тотучы картны
Үчекләргә баралар.

Менә берәү күпердә
Аръякка кичеп бара.
Елга аша чыга да,
Китә урманга таба.

---

Оҗмах кебек диярсең,
Силби — чуваш авылында.
Вакыт үткән сизелми
Шатлык, рәхәт астында:

Адәм тавышы, кош җыры
Тирә-якка тарала.
Язгы матур көн җыры
Яңгырый, гөрли һавада.

Урам буйлап кешеләр,
Албутмыни, баралар.
Өй артында шаулашып,
Уйный шаян балалар.

Нар[1] күк чибәр яшь кызлар,
Аккош кебек атлыйлар.
Чылдыр-чылдыр тәңкәләр
Чылтырыйлар, яңрыйлар.

Җир җимереп егетләр
Бии капка алдында.
Тормыш матур, аһ, матур,
Олы Силби авылында!

---

Шушы якты дөньяда
Юктыр адәмнән көчле;
Җирдә, суда — һәркайда,
Йөри ул хуҗа төсле.

Ләкин көчле адәм дә
Дөньясына буйсына.
Акча белән эчемлек
Аның акылын туздыра.

Бөек калым[2] атнада
Кайсы чуваш эчми соң?

---

[1] Нар — легендар образ. Чувашларда матурлыкка, гүзәллеккә, сәламәт тазалыкка образ булып йөри.
[2] Калым — язгы, дини бәйрәм.

Тирэн нәүрәп эчендә
Күпме сыра бетми соң?

Ашадык та, эчтек тә,
Уйнадык та вакытында,
Шунсыз бәйрәм — нәрсә ул,
Безнең чуваш каршында?

Көн үтә дә, урамда
Исерек кешеләр арта,
Кичке тавыш яңгырый
Бөтен җиргә, як-якка.

---

Эчә-эчә кичкәчә
Чуваш исерә, күбенә,
Ял иткәндә, балчык та
Түшәк булып күренә.

Ята чуваш албут күк,
Белми кайда торганын,
Бөтен урам буйлата
Акыра исерек җырларын:

Күп эшлә дә, күп аша,
Күбрәк тирлә, күбрәк эч!
Моның өчен кем сүгәр?
Ул бит шундый күркәм эш!

Вакыты белән эшлибез,
Вакыты белән эчәбез!
Өйдә сыра булмаса,
Күршеләргә керәбез.

Күршеләрдә булмаса,
Әйрән бар ич, эчәбез.
Шул әйрән дә булмаса,
Тугры[1] бирер, көтәбез!

---

Калым үтә, кар бетә,
Язгы сука да җитә.
Чуваш кайчанга айный?
Махмыр кайчанга китә?

---

[1] Тугры — алла, ягъни тәнре.

Инде, исерек чувашлар,
Вакыт сезгә торырга!
Биек үрләр ямь-яшел,
Сулар кибә болында.

Әй туганнар, торыгыз!
Тирә-якка багыгыз!
Әзер булсын арбагыз
Яки сука башыгыз.

Салкын суда юынсаң,
Биткә күзгә төс кертер.
Яхшы итеп аша, эч —
Язгы эшкә көч кертер.

Язгы чәчүгә китик,
Атны тизрәк җигегез!
Әй, бер тугрым, саулык бир,
Уңсын чәчкән җиребез!





## 2. ГҮЗӘЛ КЫЗ

Яшел үлән астында
Татлы кызыл җиләк бар.
Силби — чуваш авылында
Нарспи атлы чибәр бар.

Бите-күзе бик нәфис,
Язгы чәчәк — кыз бала.
Ике кара ахак күк,
Ике күзе чем-кара.

Озын толым бөдрәле,
Җем-җем уйный чәчләре.
Атлап-атлап барганда
Чыңлый көмеш тәңкәсе.

Күзе белән бер бакса,
Егет җаны рухлана.
Нечкә ирене бер көлсә —
Егет җаны нурлана.

Кызыл ялан чәчәген
Кемнәр өзелеп сөйми соң?
Шундый матур кыз өчен
Нинди егет көйми соң?

Кояш иңгәч, су белән
Битен, кулларын паклый.
Чыгар өчен уйнарга,
Киенә, бизәнә башлый.

Көмеш япма төшендә,
Артта чулпылар чыңлый,
Кызыл ефәк шәлен ул
Җитез кызларча чолгый.

Уйнаганда бер тоташ
Көлә, жырлый, шаулый ул.
Чулпан йолдыз чыкканчы,
Сандугачтай сайрый ул.

Таралгач та уеннан,
Җанга рәхәт калдыра.
Таңгы йолдыз түбәдә
Җем-җем нурын балкыта.

Әткәсенең йортында
Татлы йоклый шат бала.
Матур-матур төш күреп,
Төшендә дә шатлана.

---

Иртүк тора, киенә,
Күңелен эшкә бирә ул,
Я ефәк җеп ала да,
Җырлый-җырлый чигә ул.

Я ул, тезмә эз салып,
Тегә башлый тын гына.
Сүс койрыклы корыч эт
Бер керә дә, бер чыга.

Я ул суса уйнатып,
Киндер тукый бер вакыт.
Я ул тора уйланып,
Шүреләргә җеп катып.

Яки, мәче сәкедә,
Битен юып, сөртенсә,

Житез кызый аш ясый,
Кунак өчен, йортында.

Яхшы үтте тормышы,
Яшькә, буйга житкәнче.
Жиде яттан яучылар
Әткәсенә килгәнче.

---

Михәдәр күк маллы юк,
Тирә-якта кайда да,
Ярата ул үз кызын,
Аның белән мактана:

— Минем кыз күк кайда бар?
Бер кемдә юк, күрәмсең?
Миндә бит ул гүзәл кыз,
Матур, нәфис күгәрчен!

Матур аның рәвеше,
Әйтерсең бер хур кызы!
Юкмы читек-кәвеше?
Юкмы көмеш чулпысы?

Силби авылы гомер дә
Андый кызны күрмәстер!
Бер чуваш та үз кызын
Михәдәрдәй сөймәстер!

Михәдәргә ни житми?
Йорты гажәп мул, бай шул.
Көмеш тәңкә бихисап,
Нәрсә кирәк, шул бар шул.

Ни юк дисең нәүрәптә?
Яки менә базга бак!
Мичкә-мичкә сыра, бал,
Май, сөт, катык — бар да бар.

Киез, киндер гаять күп,
Мул да, күп тә барысы.
Келәт тулы, туп-тулы,
Ясмык, бодай, тарысы.

---

Дөрес сүздә алдау юк,
Михәдәрдә бар да бар.
Тирә-якта аңарга
Тиңгә килми башка бай.

Аның йорты — кала күк,
Җил дә керә алмаслык,
Каралтылар бик биек,
Чыпчык менә алмаслык.

Аның йорты — кала күк,
Бөтен җирдә мал-милек.
Келәт-келәт игеннәр,
Абзар гөрли шау килеп.

Аргамак күк шәп атлар,
Солы-печән ашыйлар,
Йөри шунда терлекләр,
Мичкәләргә ошыйлар.

Йортта мөңри сыерлар,
Шаулый йөзләрчә сарык.
Чыр-чу килә, болыт күк,
Үрдәк, күркә, каз, тавык.

Тури-гаста [1] шул бай өй,
Күңелең тартып тора.
Ерак-ерак җирдән дә,
Күренеп, балкып тора.

Шундый бай ул Михәдәр,
Мактанырга хакы бар.
Карт булса да мәһабәт,
Байлык белән даны бар.

---

Шул яхшы бай Михәдәр
Кызын чиксез яратып,
Масленица көнендә,
Куйды иргә ярәшеп.

---

[1] Тури-гас — югары урам.

Әй туй булыр, туй булыр,
Менә тиздән күрербез!
Бөтен авыл мул туйны
Көтә хәзер түземсез.

Туйлар монда зур булыр,
Иркен булыр, мул булыр.
Бөтен якка дан китәр,
Нәрсә кирәк — шул булыр.

Килен артык гүзәл шул,
Килен матур шул, диләр.
Затлы байлар берләшсә,
Шәп тә булыр, туй, диләр.

Симек[1] кайчан җитәр соң?
Ничек шунча чыдыйк соң?
Симек — көннәр житкәнче
Ничек түзеп торыйк соң?

Михәдәрнең йортында
Бирнә-фәлән ясыйлар.
Эшли-эшли туйга дип,
Эштән чыгып арыйлар.

Ләкин Нарспи гүзәл кыз,
Кайгы-моңда ярсый ул.
Яшерен-яшерен елаклап,
Сәтнәр исемен ятлый ул.

Хәзер Нарспи, гүзәл кыз,
Һаман-һаман моңлана.
Тиздән булыр туй, дигәч,
Кайгырта да, шомлана.

Авыл чите — Тугаста[2]
Фәкыйрь бер өйчек тора.
Караңгылык, каралык,
Моңсу төс бирә моңа.

---

[1] Симек — бер атнага сузыла торган дини бәйрәм, русларда троица дип йөртелә.
[2] Тугас — тури-гас, югары урам.

Һәр көн шул йорт эченә
Кич тә житми, төн керә.
Карчык әнкәсе белән,
Сәтнәр шунда көн күрә.

Чибәр егет Сәтнәрнең
Бер аргамак — даны бар.
Карчык әнкәсе белән,
Кайнар йөрәк — җаны бар.

Байга эшләр эшләргә
Көчле беләк — кулы бар.
Дошман көчен җиңәргә,
Нәфрәт, куәт, рухы бар.

Аннан башка Сәтнәрдә
Берни дә юк, аз гына,
(Тик бел: кызын, Михәдәр,
Бирмим, дияр, ярлыга.)

Безнең Нарспи гүзәл кыз,
Сәтнәр — бәгърен сөя ул.
Шул сәбәптән гүзәл кыз,
Туй булганга көя ул.

Биек улак каршына
Талдан шәүләләр төшә.
Һәр көн шунда таң саен
Сәтнәр Нарспины көтә.

Көтә-көтә күп тора,
Җитез атын сугарып,
Нарспи килә таң саен
Чиләк тотып, суга, дип.

Нарспи чиләк чайкатып,
Шалтыр-шолтыр киләдер.
Шатлык белән Сәтнәрдә
Йөрәк дөп-дөп тибәдер.

Нарспи килә ерактан
Көлә-көлә нурланып,

Биек улак башында,
Сәтнәр тора рухланып.

Елтыр-елтыр күзләре
Гүзәл кызга багалар.
Сары мыек иреннән
Җылы сүзләр ташалар.





## 3. СИМЕККИЧЕ

Челдер-челдер су ага
Биек улак буйлата.
Көмеш кебек ялтырап,
Суын кояш нурлата.

Биек улак буйлата,
Челдер-челдер су ага,
Көмеш-мәрҗән такыялы
Матур кызый су ала.

Акрын-акрын су тула,
Яшел чиләк эченә.
Сөйли-сөйли яшь егет,
Ярсу атын эчерә.

Биек талда, яшеренеп,
Кошчык җырларын көйли.
Чапкын аткай эчкәндә
Егет сүзләрен сөйли.

— Шулай итеп, Нарспием,
Куәт юкмыни миндә?
Шулай сине бер усал
Алырмы икән ят җиргә?

Ах, бәхетем юктыр шул,
Әткәң-әнкәң бай булгач,
Алар шулай байлык белән,
Мин фәкыйрьгә сүз кушмас...

---

— Хафаланма, әй Сәтнәр!
Нигә өмет кисәргә!
Шул бай әти-әнидән
Кая качып китәргә?

Әти-әни ахмак шул,
Ни дип юатыйм тагын?
Ни эшләргә, әйтче син,
Ничек юл табыйк, җаным?

Кояш иңгәч, кич булгач,
Бүген туйны җайлыйлар:
Хушылка[1] бае белән
Минем туйны башлыйлар.

Дошман бик усал, диләр,
Ничек аннан котылыйм?
Сәтнәр, Сәтнәр, әйтче син,
Кайда китим, ни кылыйм?.

Сине җаным күк итеп,
Яратып гомер сөрдем.
Ләкин менә бу көнне
Яшь башым белән күрдем.

---

— Кайнар канлы йөрәгем,
Бердән-берем — башым бар,
Тагын карчык әнкәм бар,
Аргамагым — җаным бар.

Барысыннан да яхшырак —
Син, сөйгәнем, ярым бар.
Ләкин сине дә бүген
Тартып алыр — явыз бар.

---

[1] Хушылка — авыл исеме.

Ул дошманны бетерер —
Көчле куллар миндә бар.
Ләкин аны юк итсәм,
Аннан усал дөнья бар.

Теләк булса үзеңдә,
Шушы атка салырмын.
Бу авылдан еракка
Очармын да качырмын.

— Сәтнәр, югал тизрәк син!
Суга килә бер хатын...
Синең белән сөйләшеп,
Аерылганым тоймасын...

---

— Сау булм, минем Нарспием,
Сау бул алайса, иркәм!
Хәтерлә мин мескенне,
Чыгарма син дә истән!

Аргамак күк җитез ат
Сикерде дә җилкенде.
Очып китеп, Сәтнәрне
Өйгә чаклы җиткерде.

Нарспи аны, кайгырып,
Карап калды туйганчы.
Кузгалмады урыныннан
Ярын күздән җуйганчы.

— Сау бул, бәгърем, сау булчы!
Ничек синсез калыйм соң?
Синең белән булмыйчы —
Ничек ятка барыйм соң?

— „Нидән, Нарспи, син болай
Кайгырасың шул чаклы?
Әллә кияվең картмы?
Әллә хәсрәтең бармы?

Әллә бирнә азгамы?
Нинди кайгы соң тагын?“

Килеп җитте дә аңа,
Әйтте баягы хатын.

Нарспи, суын алды да,
Өйгә китте моңсынып.
Өйгә җитте, яшен түкте,
Сәтнәр өчен борчылып.

---

Өйдә гел юкка карчык
Йөри орышынып, ярсып.
Сипли тышта Михәдәр
Туй күмәсен [1] бер ялгыз.

Кызы өчен эшли карт
Балта белән — шак та шык...
Бөтен бите буйлата
Тама тире тап та тып.

— Мин кызымны үстердем,
Җитте шул яшькә килеп.
Хәзер инде кызыма
Соңгы эшем бу минем.

Үсеп җитте, булды кыз,
Кияү маллырак кирәк.
Кияве дә таптык та,
Күмә җайлырак кирәк.

Җитте инде симек тә,
Кызым туен җайларга,
Кардәшләрем җыелса,
Кичкә туен башларга.

---

Михәдәрнең өендә
Сыра мичкәсе ауный.
Бөтен кардәш-туганның
Тамак төпләре ярсый.

[1] Күмә — матур кибитка, өсте күн белән ябылган арба. Туй өчен махсус шундый күмә ясау чувашларда элек характерлы була.

Ике зур мич эчендә
Төрле ашлар парлана.
Бөтен кардәш-туганның
Авызы-ирене майлана.

Кара өйдә шыбырчы[1],
Шыбыры тынып тора.
Шунда егет-җиләннең
Табаны кычып тора.

Туйның рәхәтен күтеп,
Бары да оча да чаба.
Өйдә бер җан кайгысын
Һичкем сизми ләбаса.

Нарспи тора келәттә
Коймагын каба-каба.
Күрәчәген кайгыртып,
Хәсрәткә кала-кала.

---

„Җиде яттан килде ят,
Әткәйгә димче килде.
Җиде ятның баена
Чәчәктәй кызын бирде.

Әткәй-әнкәй, туктагыз,
Тагын бер ел торыгыз!
Бар бердәнбер кызыгыз,
Тагын бер ел тотыгыз!

Әткәй-әнкәй исерекләр,
Минем хәлгә кермиләр.
Кияү артык бай имеш,
Минем җанны белмиләр“.

Әй карт җан да каты җан!
Катып киткән таш шул ул.
Әй яшь җан да нәни җан,
Артык йомшак җан шул ул!

---

[1] Шыбыр — чувашларда милли музыка коралы.

Әй җаным кош булсын ла,
Еларга да, көләргә!
Канатларым булсын ла,
Очарга да китәргә!

---

Кояш төште кызарып,
Кара урман артына.
Көтү төште гөрләшеп
Олы Силби авылына.

Әнә җитез яшь кызлар
Сыер артыннан чаба.
Чая, матур егетләр
Алар артыннан бара.

Әнә бәрәү йөгерә,
Ала сыер мөңрәнә.
Ахмак чучка чиный да,
Бөтен авыл тетрәнә.

Көтү узгач, урамда
Кара тузан кузгала.
Менә шунда бер карчык
Бер атлый, бер туктала.

Менә сыңар кул белән
Сыра чәркәсен алды.
— Ай-һай газап бик авыр!
Ай-һай эчү бик яхшы!

---

Кардәшләрен чакыра
Безнең Михәдәр абзый.
Сыра тотып, тузанда
Аның карчыгы атлый.

Кардәш-дуска керә дә,
Сыра бадьясын ача.
Туйга дәшеп эчертә
Туйның сырасын аңа.

— Якын кардәш-туганнар!
Безгә шатлык бирәмсез?

Кызны иргә тапшырдык,
Тури-гаска киләмсез?

— Барабыз да, барабыз!
— Бармый-нитми калмабыз!
Алла бирсә, сау булсак,
Сүзең читкә какмабыз!

Карчык йөри авылда
Караңгы төшмәс борын.
Карчык йөри өендә,
Хәзерли икмәк-тозын.

---

Якын кардәш-туганнар,
Тури-гаска юл алыйк!
Бәрәкәтле сырасын
Эчә-эчә туй ясыйк!

Безнең туган кыз бирә,
Чакыра бүген туйга.
Мул туен да, зур туен,
Башлый икән ул шунда.

Иске гадәт буенча —
Туйның башын каршылап,
Борынгылар рухына,
Икмәк-тозны каптылар.

Карт аталар-аналар,
Шат торыгыз җәннәттә.
Безнең икмәк-тозыбыз,
Булсын сезнең дәүләттә.

Безнең сөйгән Нарспига,
Бирегез якты тормыш!
Бирегез бәхет белән
Шатлыклы яхшы тормыш!

---

Хәтерләгәч картларны
Хәер дога-теләктә;
Аннан туйны башларга
Җыйналдылар keләткә.

Чүмеч-чүмеч сыралар,
Ата-ана хушлаша...
Ата-ана алдында
Кызый елый, хурлана.

— Нарспи, кызым, шул сиңа,
Ирең яхшы, карышма!
Аның белән матур тор,
Гомереңшуңа багышла!

Тыңла аны, юаш бул,
Усалларга тагылма!
Эшне эшлә, эшчән бул,
Юк-бар эшкә катышма!

Ата-ана вәгазьли,
Кызый яшькә батканда,
Шыбыр тавышы яңгырый,
Вакыт туйны башларга.

---

Силби авылы хырылдап,
Йоклый үлек җан кебек,
Дөнья тынлыгын күреп,
Күктә ай да шат кебек.

Җереп бетте уеннан,
Кызлар, егет-җиләннәр.
Хәзер йоклый туй халкы,
Йоклый хуҗа дигәннәр.

Җылы — һаман суына,
Колак тын да ишетми.
Тик өрә бер эт кенә,
Авызын ачкан — иренми.

Әтәч төнлә кычкыра,
Тагын йокыга тала.
Акрын-акрын ак ай да,
Урман артына бата.

Тыныч, татлы йокыда
Чуваш йоклый, тик менә —
Шул кич газап эчендә
Бер яшь йөрәк тилмерә...



## 4. ТУЙ

Кояш чыгар-чыкмас чак —
Төтен күккә менәдер.
Күзне ачар-ачмас чак —
Чуваш мунча керәдер.

Симек йоласы белән
Мунча керәләр барысы.
Симек чирәме белән
Ышкыйлар тәнне, башны.

(Шулай кушып калдырган
Безгә әби-бабалар);
Шулай бүген чувашлар
Мунча кереп калалар.

Өстен-башын һәйбәтләп,
Матур киемнәр белән;
Барыда чыкты урамга,
Туйны күрергә теләп.

Атладылар иртәнчәк
Акрын-акрын, бер җайга.
Атладылар урамда
Туйны күрергә бары да.

Менә туй да, менә туй!
Бездә туйлар шул чикле!
Тури-гаста туй тавышы,
Яңгырата бар җирне.

---

Михәдәрнең йорт-җире
Ерактан балкып тора.
Урам якта, капкадан,
Кем керә дә, кем чыга.

Йорт алдында халык күп,
Туйны карарга килгән.
Карт-коры да аз түгел,
Сыра кагарга килгән.

Җилкетеп тә, сикертеп,
Янрый шыбыр тавышы.
Яхшы хуҗа хакына
Туй гөрләтә туй халкы.

Туйда халык туй итеп,
Талчыга да, шатлана.
Шыбыр тавышы басылгач,
Туй җырлары башлана:

— Ник соң тыныч торасыз?
Ник соң тыныч болай сез?
Тыныч-тыныч торырга
Былбыл баласымы без?

---

Ләкин шыбыр холыксыз,
Һаман биергә дәшә.
Дөбер-шатыр биюдән
Өйләр селкенә ләсә!

Ашап-эчеп сыйлана
Кунаклар түр башында.
Яхшы теләк телиләр
Кыз да кияү хакында.

— Кыз да кияү сау булсын!
Балаларга тап булсын!

Матур, тату көн күрсен,
Усал сүздән сак булсын!

Аша, уйна, җырла, көл,
Күтәрелсен күңелләр!
Бергә,бергә, бергә чак —
Бергә үтсен гомерләр!

Әйдә, кардәш-туганнар,
Эчик-эчик тә ашыйк!
Кияү, кызны хөрмәтләп,
Әйдә шәбрәк туй ясыйк!

Менә инде, күр инде,
Ничек бии карт хуҗа!
Кызын биргән, йорт башы
Шатлана бүген шуңа!

---

Матур егет-жиләннәр
Бөтен көчкә басалар,
Кызлар тагын калышмый,
Такмак әйтеп баралар.

Ефәк чигүле чаршау,
Түбәнгә төшә бара.
Кызыл чаршау эчендә,
Бөркәнчектә кыз бала.

Кыз елый да кыз елый,
Бөркәнчеген салмыйдыр.
Дус кызларның җырлары —
Аның тавышын каплыйдыр.

Кызлар мактап Нарспины —
Җырлыйлар матур җырны,
Михәдәрнең Нарспиен —
Туен үткәргән кызны!

Бер чал сакал Тохтаман,
Кияү булып киләчәк.
Җаны сөйгән ярыннан
Яшь кыз ерак китәчәк.

Әгәр ятка китсәң син,
Сәтнәр ни хәл итәр соң?
Сылу Нарспи, әй туташ,
Бәхетең кайда икән соң?

---

Җир җимертеп туй бара,
Аның чиге-башы юк,
Кардәш-туганнар йөри,
Алар күбәү — саны юк.

Зур көн күмә янында
Кардәш кызлар урала.
Шул кызларның җырлары
Ерак китеп, югала.

Көнен-төнен уйнарга —
Шыбыр һич тә тартынмас.
Көнен-төнен җырларга,
Егетләр дә талчыкмас.

Бала-чага һәр җирдә
Кызыклар күрми калмый.
Үлек күк бер карт кеше
Тәрәз төбендә калгый.

Туй бара да шәп бара,
Карт кешенең хәле юк,
Бии яткан җирдә дә,
Ләкин һич тә рәте юк.

## 5. БАГУЧЫ ЯНЫНДА

Кеп-кечкенә кара йорт,
Сәкедә карт, чал чәчле.
Якты керми бераз да,
Тәрәз нәни шул хәтле.

Өйнең эчен яктырта
Тик ачык ишек кенә,
Идән буйлап кояшның
Нуры шуышып керә.

Түрдә тора карт ялгыз,
Ямый-ямый чабата.
Аяк белән, кул белән
Мыш-мыш килеп маташа.

Менә кояш яктысы
Шуып та шуып барды.
Картның чал чәч башына
Килде дә кунып калды.

Симек шавы урамда,
Йөрәк хисен кузгата.
Әх, кояш та уйнаклап,
Чәч бөртеген нурлата.

Мыгырдап та, мышылдап,
Бабай чабата сипли.
Шунда, ләкин бөтенләй,
Кунак килгәнен сизми.

Ачык ишек төбенә,
Бер карчык килгән икән.
Чал чәчле карт бабайга,
Сәламнар биргән икән.

Сәтнәр анасы икән —
Бабайга сүзен кушкан.
Аның газиз улына
Усал шаукым — чир булган.

Шуңа күрә анасы
Багучы янына килде.
Аһ-зар белән бабайга,
Кайгысын сөйләп бирде.

Алар карт белән озак
Сөйләштеләр калыгып,
Кай чак сүзгә җай килсә,
Үткән чакны сагынып.

Соңра бабай, ниһаять,
Багуның хакын куйды.
Карчык, бер пар оек та,
Күлмәк бирергә булды.

Аннан бабай торды да,
Эшләрен ташлап читкә,
Ябып куйды ишеген,
Табагач белән бикләп.

Тунын кигәч, бүреген
Тыкты култык астына.
Табан-аска кыл салып,
Акча куйды алдына.

Аннан аксыл сакалын,
Көмеш чәчләрен сыйпап,

Акчага карап торды,
Барлык гайрәтен җыйнап.

Багып торды-торды да,
Җитен сакалын тарап;
Тезеп-тезеп сөйләде,
Карчыкка таба карап.

„Маңгай тишеге — капланмас,
Йөрәк кисеге — кушылмас.
Пулех [1] тәңре язганнан
Улың һич тә котылмас.

Биргән аңа пулехче[1]
Кайнар кан да, йомшак җан.
Биргән аңа пулехче
Кыска гомер, хәсрәт-зар.

Суык көннәр килер дә,
Туңып китәр кайнар кан.
Каты көннәр килер дә,
Катып китәр йомшак җан.

Кайнар көннәр килер дә,
Кайнарланыр салкын кан.
Йомшак көннәр килер дә,
Йомшакланыр каткан җан“.

Аннан, бабай тукталып,
Сагышланып торды да,
Ертык тунын, бүреген,
Читкә салып куйды да,

Шунда, тагын сөйләде,
Баккаларга тотынып;
(Тора карчык сәкедә,
Арлы-бирле борылып).

---

[1] Пулех — пулехче — чувашларда борынгы мәҗүси илек алласы.

„Төрле шаукым килмәгән,
Кирәмәт[1] суккан түгел.
Ерех[2] хәстә бирмәгән,
Сихерләп куйган түгел.

Юк, юк, килен, улыңа
Ходай шулай язгандыр.
Елый күрмә, тәңрегә
Каршы тора алмассың".

Бабай шулай сөйләде,
Ни кылырга белмәде.
Үз эшләрен көйләде,
Башка сүзгә кермәде.

Карчык чыкты кайгырып,
Башын түбәнгә салды.
Чабатасын төзәтеп,
Бабай утырып калды.

Мыгырдап та, мышылдап,
Аптырый да үкенә.
— „Нигә болай бу бүген?"
Сорау бирә үзенә.

„Хәзергәчә халыкка,
Багулар бага идем.
Юк-бар әйтеп, алдалап,
Озатып кала идем.

Нигә болай бу бүген?
Йөрәк чынга тап микән?
Алдалармын дидем дә,
Ах тамаша! Расмы икән?"

---

[1] Кирәмәт — явыз, усал рух, мәҗүсилектән калган. Элек чувашлар кирәмәт дигән калын, карт һәм „изге" агачка табынганнар, аның явызлык эшләвеннән куркып аңа төрле бүләкләр, сыйлар китереп торганнар.

[2] Ерех — явыз, усал рух, мәҗүсилектән калган.



## 6. КАЧУ

Кояш бата, кич керә,
Силби авылы тын менә.
Караңгылык төшкәндә,
Туй тарала, туй бетә.

Матур кызлар, егетләр
Урамга чыкты тагын.
Чыкты безнең Нарспи да
Озатып яшьлек чагын.

Соңгы кичтә уйнарга,
Хатын булып җиткәнче.
Соңгы кичтә Сэтнәрне
Күрер өчен, киткәнче.

Сэтнәр тора кайгырып,
Башын бөгеп, тын гына.
Матур кызның күзеннән
Кайнар, кайнар яшь чыга.

Уйнаучылар таралгач,
Җәйнең жылы төнендә,

Алар байтак тордылар,
Зифа таллар төбендә.

Алар шулай, шул төндә,
Көткәннәрен таптылар;
Кочаклашып бер-берен,
Урманлыкка качтылар.

Вак йолдызлар еракта
Балкып янмый башлады.
Урман өстен кап-кара,
Шомлы болыт каплады.

Яңгыр ява, су төшә,
Кара урман гөр килә.
Улый гүя ач бүре —
Җил чыга да, җил китә.

Яшен уйный, ялтырый,
Шаулы урман яктыра.
Кара урман эченнән
Чапкын алга ашкына.

Чапкын бара, пошкыра,
Шомлы юл артта кала.
Йончыла ул — кыз да егет
Аңа атланып чаба.

Агач тора алып күк,
Караңгыда шау килеп.
Әйтә: „Чибәр үтегез“,
Башын бөгә җай биреп.

Таң алдында яп-якты,
Кояш чыгар — чибәр чак,
Таң алдында ак офык,
Туйга вакыт җитәр чак.

Егетләргә биешергә
Вакыт җитәр — яхшы чак.
Кызларына жырларга
Вакыт җитәр — якты чак.

... Шыбыр тавышы ишетелми,
Уйнаучысы күренми.
Кунак-төшем алдында,
Сыра-фәлән түгелми...

Карчык белән Михәдәр,
Кара өйдә талаша.
Ни булды соң бу болай?
Бары да тыныч лабаса?

Тыныч-тыныч торырга
Нарспи йортта юк ласа.
Сәтнәр белән, кич-кырын
Качып китkәч, юк чара!

Урманда өч атлы бар,
Нәрсә эшлиләр алар?
Бер анда да, бер монда,
Кемне эзлиләр алар?

Эзлиләр дә тыңлыйлар,
Берәр тавыш килмәсме?
Кояш чыга яктыртып,
Кирәк юлны бирмәсме?

Ләкин һич тә күз җитми
Бөтен җирне карарга.
Шунда кемдер мыгырдый:
— Ничек тизрәк табарга?

Урман кара, бик шаулы,
Урман улый давылда.
Эз билгесез кайда да,
Хәзер кайда барырга?

Урманда өч атлы бар,
Нәрсә эшлиләр алар?
Бер анда да, бер монда,
Кемне эзлиләр алар?

Сәтнәр йоклый үлечә,
Биек имән шыгында.

Нарспи калгып утыра,
Сөйгәненең кырында.

Менә Нарспи төш күрә:
Җил-давыл купты имеш,
Аның усал әткәсе
Бер көчек булды имеш.

Менә Нарспи төш күрә:
Киң урман ыжлый имеш.
Аның усал әткәсе —
Шул көчек — ыргый имеш.

Казык тешен ыржайтып,
Ямьсез шыкырдый имеш.
Этнең табан астында
Урман шытырдый имеш.

— Кайда качтың, усал кыз?
Башың ашыйм, табылсаң!
Кайда киттең, усал кыз?
Җаның алам, карышсаң!

... Әнә җитә, аһ, якын!
Нарспи күзләрен ача...
Әнә килә өч атлы,
Сәтнәр белмичә ята.

— Сәтнәр, Сәтнәр! Тор, җаным!
Тор, тор! Тизрәк качыйк без!
Ай беттек лә, ай беттек!
Кайда, кайда барыйк без?

Бүген, матур шыбырчың,
Тагын башка юлдашлар;
Сәтнәр белән Нарспины
Тотып килде урманнан.

Карчык җилеп чыкты да,
Кунды Нарспи чәченә.
Карт та чабып чыкты да,
Сукты Сәтнәр башына.

— Әй, әнкәем, әнкәем!
Чәчем борма, кит зинһар!
Шулай өйрәтер булсаң,
Хөрмәт көтмә син миннән!

— Әй, Михәдәр бабакай!
Көлдән мәңге ут булмас!
Күпме бүген кыйнама —
Бер файда юк, ул булмас!

Шундый сүздән Михәдәр,
Тагын эттәй котырды.
Бәйләп куйган Сәтнәрне,
Камчыларга тотынды.

---

Йортта халык бик тә күп,
Гүя туйга тулган күк.
Сәтнәр шунда, туфракта,
Ята вафат булган күк.

Әнкәсе дә шушында,
Тора елап, кайгырып.
Җибәрә ул баласын,
Кешеләргә тапшырып.

Ата-ана Нарспиның
Битен-күзен юдырта,
Тагын чаршау артына —
Бөркәнчеккә утырта.

Тыпыр-тыпыр тыпырдат!
Әйдә туйда сиптертик!
Ләкин кызның качканын —
Тохтаманга сиздермик!

Менә туй да менә туй!
Матур туй да батыр туй.
Менә туй да менә туй!
Кызык туй да бозык туй.



## 7. ИКЕ ТУЙ

Көн авыша, язгы кояш,
Түбәнгә төшә башлый.
Ерак түгел дөм урман,
Нигәдер артык шаулый.

Халык көтә бик озак,
Түбән капка каршында.
Берәү кинәт, „килә“ дип,
Шатландыра барысын да.

Дөбер-дөбер сикереп,
Чокыр-чакыр юллардан,
Матур туй да, кызык туй,
Килеп чыкты урманнан.

Алдан бара юл белән,
Чырайларын бозгалап,
Силби кызын күрергә —
Яңа кияү Тохтаман...

Ялпак борын, кысык күз,
Сары чәч тә чал сакал.
Атлар очып барганда,
Бите-күзе һай хәтәр!

Кара чикмән, шәп бүрек,
Маңгаенда тәңкәсе.
Ак тула да чабата,
Әй килешә гәүдәсе!

Шул ир туе җырлашып,
Урам буйлап атыла.
Яхшы кияү капкасы
Ачыла да, ябыла.

Кыз туе да Тугастан,
Килеп чыга каршыга.
Нарспи яулык астында
Елап бара, кайгыра.

Сылу кызның йөрәге
Утта янгандай яна.
Карт киявен күрә дә,
Елап кайгыра аңа.

— Әй, әткәем, әнкәем!
Ник башыма җиттегез?
Җиде ятның кулына
Кызыгызны бирдегез?

Әй, киявем Тохтаман!
Һичбер рәхәт бирмәмен!
Минем җаным бетсә дә,
Синең белән китмәмен!

---

Сыра тоткан бер яучы.
Туйга каршы чаба ул.
Хушылканың күркенә —
Такмак үреп бара ул.

Кулы белән чайкатып,
Сыра түгә, таштыра.
Кара аткай тик тормый,
Яңа кияү чаптыра.

Яңа кияү кырында,
Бии җиде атменәр.
Бөтен авыл, җимертеп,
Гөрли матур яз белән.

Яңа, матур капкадан
Арба кереп барганда,
Капка башы шакылдый,
Камчы тиеп калганда.

Бүген кияү янында,
Туйда рәхәт сөрделәр,
Башка көнне авылда,
Кунак булып йөрделәр.

Хушылкадан килгәннәр —
Өч көн, өч төн яттылар,
Туйны ясап, сыйланып,
Алҗыдылар, ардылар.

Ләкин өч көн үткәчтен,
Сөйләнәләр „кайтыйк“ дип.
Сөйләнәләр кодалар,
„Бүген китик, калмыйк“ дип.

Һәм ир туе җыйнала,
„Хушылкага күчтек!“ дип,
— Хәзер бездә туй булыр,
Монда туйны күрдек, дип.

— Ашыкмагыз, кодалар!
Башка өйгә барыйкчы!
Китмәс борын, бу туйны
Шәбрәк ясап калыйкчы!

Тагын-тагын бер тоташ
Туйны дәвам иттеләр.
Бетте таныш-туганнар,
Туйны тәмам иттеләр.

Һәм ир туе шау килеп,
Өйгә таба кузгалды.

Туй озату вакытында,
Бөтен Силби җыйналды.

---

Олы зыярат янында,
Туй атлары торалар.
Кызны, әткә-әнкәсе,
Озату өчен баралар.

Туй янында кешеләр,
Гөбердәшеп торалар,
Әби-бабаны хәтерләп,
Кызны карап калалар.

Авыру Сәтнәр шушында,
Тора анасы белән,
Эзли сөйгән Нарспиен,
Күзе — карашы белән.

Михәдәр дә, карчык та,
Кызны бәхил кылдылар,
Кардәш-дусны елатып,
Кайнар яшьләр сыктылар.

Сәтнәр белән урманга
Көлке булып качканга,
Сөйгән кызга бер сүз дә
Әйтмәделәр барганда.

---

Бәхилләшкәч, эш беткәч,
Туй да китте ашкынып.
Сәтнәр йөзен күргәч тә,
Нарспи елый ярсынып.

Туй киткәч тә, ерактан
Урман каты яңрады.
Туй югалгач, кешеләр —
Бары да өйгә атлады.

Кайтып китте кайгырып,
Сәтнәр, анасы белән,
Калды шулай кавышмый,
Йөрәк парасы белән.

Әй бу тормыш, бу тормыш!
Ләкин үлем житте шул.
Әй бу тормыш, Нарспи да
Җиде ятка китте шул.

Ансыз башны нишләтим?
Калдым кыюсыз баш белән.
Кайда барып керим соң,
Шундый хәсрәт-зар белән?

Нарспи китте чит җиргә,
Сәтнәр өйгә атлады.
Бу ике җан, гашыйк җан,
Байны җиңә алмады...

Гашыйкларның качканын,
Урман каплап тормаган.
Матур кызны — Нарспины
Алды, алды Тохтаман!

Торып калды бер ялгыз,
Сәтнәр — ярлы баласы.
Бәлки ходай язгандыр,
Шулай, ахыры, заманы.

Бик күп аның турында,
Фәлән-төгән сөйлиләр.
Тик, күп аңлы ирләр дә,
Рәтен-чабын белмиләр.

Сәтнәр калды бәхетсез,
Сөйгән кызын алдылар.
Нарспи китте чит җиргә,
Хәсрәт-моңга аттылар.

Ашадылар туй белән,
Кунак — кунакның башын,
Әткә, әнкә — кыз башын,
Туган — туганның башын.



## 8. ХУШЫЛКАДА

Хушылкада туй икән,
Туе бигрәк мул икән.
Чал сакаллы Тохтаман —
Туй җыйнаучы — шул икән.

Чибәр кияү Тохтаман
Силби кызын хур итә,
Бүген, яхшы тиңнәргә —
Дөбер-шатыр туй итә.

Матур кияү-егетләр
Бии-бии туй ясый.
Туй җырларын яңратып,
Авыз арый, тел арый.

Кичә Силби авылыннан
Кайтып килде бер туе.
Кияү көтә кыз туен,
Бәйрәм бүген көн буе.

Уйлый, бүген туй килсә,
Кызны кертеп ябарга.
Иртән торган вакытка,
Кызны хатын ясарга.

Бик зур авыл Хушылка,
Тау тора һәр ягында.
Туйны ясап Тохтаман
Утыра өстәл янында.

Төрле ашлар астында
Юкә өстәл сыгыла.
Исерек кияү алдында
Дөнья выр-выр борыла.

Тышта кояш балкыта,
Кичкә таба авыша.
Кияү башы исергәч,
Аска таба салына.

Ямьле кырда бүдәнә,
Вакыт-вакыт сайрый ул.
Кияү, туйны көтә дә,
Тәмам алҗый башлый ул.

Ак бүз күлмәк кияүдә,
Җилбер-җилбер киләдер.
Туйны көтеп, йөрәге —
Һаман дыр-дыр тибәдер.

———

Чыңгыр-чыңгыр кыңгырау,
Атлар ыргый юллардан.
Җир җимертеп кыз туе,
Килеп чыкты урманнан.

Унлап хатын хушбулы[1]
Күн күмәнең алдында.
Кырык бишкә якын ат,
Күн күмәнең артында.

Җиде жирдә, урамда,
Туктап алды туй халкы,
Якын туган-тумача,
Чыкты боларга каршы.

---

[1] Хушбу — матур тәңкәләр белән бизәлгән, хатын-кыз баш киеме. Элек алар туй һәм бәйрәм вакытында шундый хушбу кигәннәр.

Җырлыйлар да керәләр,
Кияү капка ачкачтын.
Ашыйлар да эчәләр,
Ерак юллар ашкачтын.

Күрче, төш тә җитмәгән,
Кичкә вакыт күп әле!
Төнгә кадәр туй ясыйк,
Бик тә вакыт күп әле!

Аш-су белән сыйланып,
Сикерделәр, ардылар.
Тохтаманны, Нарспины,
Ак келәткә яптылар.

Зирәк ирләр келәткә
Таза йозак салдылар.
Пыш-пыш көлә-көлә тик
Өйгә таба чаптылар.

Менә егет, бер егет,
Келәт буен сагалый.
Тыңларга да карарга —
Аулак урын чамалый.

Бала-чага биш-алтау
Келәт карый бер якта.
— Әх, намуссыз малайлар!
Ни эшегез бар анда?

Ләкин менә тыңлыйлар,
Тавыш килә: пыш та пыш.
Тынып калды малайлар,
Шауламагыз, сөйли кыз!

Шунда Нарспи нәрсәдер,
Сөйләгәндә туктады.
Ләкин тавыш бик акрын,
Бер ни ишетеп булмады.

— Бел син, Нарспи, тезгенең
Хәзер минем кулымда! —
Диде усал Тохтаман,
Ачу белән шушында.

— Туйны кире озатыйм,
Аннан мине белерсең!
Ни буласын кем әйтер?
Ни күрәсең күрерсең!

Башка берни ишетелми,.
Һичбер сүз дә килмәде
Тыштагылар көтсә дә,
Һичбер тын да сизмәде.

Бала-чага шушында,
Өйгә чабып китәләр.
Ишеткәннәр турында
Яшерен хәбәр илтәләр.

Тыңлап торган шул егет
Урманлыкка атлады.
Ишетеп алган сүзләрне
Күңеленнән ятлады.

Аның усал күзләрен
Ялтыр утлар бастылар.
Кергән-чыккан кунаклар,
Белми-күрми калдылар.

Ләкин урманда сизде,
Күршесен ялгыз имән.
Ул егет — безнең туган,
Яшь егет Сәтнәр икән.

---

Ботка өстәл өстендә,
Өйгә булар туздыра.
Яхшы кияү Тохтаман
Кунак-төшем туйдыра.

Яңа кияү Тохтаман —
Ботка белән майлый ул,

Туй халкына баш орып,
Сүзен шулай башлый ул:

— Үпкәләшмик, кодалар,
Сый күп түгелдер сезгә!
Ашыйк, эчик, туганнар,
Үтсен гомерләр бергә!

Топма-исерек кунаклар,
Гөбер-гөбер гөрлиләр.
Топма исерек баштан да,
Барын белеп сөйлиләр:

— Әй кияүкәй, Тохтаман!
Юк үпкәләр төшегез!
Безнең кызны каты тот,
Рәхәт гомер сөрегез!

Тышта атлар торалар,
Биеп-биеп, тавышлап,
Чыгып китте кодалар,
Матур җырлар багышлап.

„Әйдә, киттек, дан белән,
Тулы чүлмәк бал белән".
Арбаларның артыннан
Тузан купты шау белән.

Матур яңрый кыңгырау,
Атлар — Силбигә таба.
Түбән бөгеп башларын,
Атлар атлыгып чаба.

Туй бетте дә, туй китә,
Такыр юлдан сыптыра.
Берәр картны күрсәләр,
Бары да сәлам кычкыра.

Туй бетте дә, туй китә,
Атлар талчыга башлый,
Начар юлдан аларны
Исерек хуҗалар каулый...

Киткән туйның тавышын
Нарспи калды ишетеп.
Аннан-моннан, ерактан,
Тузан калды ишелеп.



## 9. СИМЕК ҮТКӘЧ

Үтте симек, үтте туй,
Үтте туйдагы рәхәт.
Үтте бер-бер тезелеп,
Көн белән төн һәм сәгать.

Кырда сабан астында
Чирәм чырт-чырт киселә;
Усал кайгы-сагыштан
Нарспи җаны киселә.

Кырда чалгы астында
Печән вышт-вышт бөгелә.
Усал кайгы-сагыштан
Нарспи башы бөгелә.

Дөнья йөзен көннән-көн
Кояш нур белән камый,
Кайгы-сагыш көннән-көн
Нарспи йөрәген талый.

Көн дә, көн дә, саламат
Төшә тора колгадан.
Каты тота шул кадәр
Үз хатынын Тохтаман.

---

Чибәр бала Сәнтти бар,
Чабып йөри урамда.
Көянтәгә атланып,
Ат-ат уйный ул анда.

Ул зур урам буйлата
Чиксез тузан кубара.
Кара чегән күк кара,
Кайта кичен бу бала.

Чибәр бала Сәнтти бар,
Чабып килә атында.
Сөйли нәни тел белән,
Җиңгәсенең янында.

Нарспи-килен һаман да,
Гел кайгыра, көя ул.
Биаганың баласын —
Тик Сәнттине сөя ул.

Нарспи-килен һаман да,
Гел сагышлый, яна ул.
Сәнтти белән сөйләшеп,
Иркен сулыш ала ул.

Шундый яхшы балада,
Тәңре җаны тора шул.
Уйный, көлә, анарда
Кошлар ирке тора шул.

Җиде яшьлек балада
Чуваш җаны тора шул.
Нәни күзе еласа —
Юаш ирене көлә шул.

Чибәр бала — Сәнтти бар,
Җанга якты бирә ул.
Татлы, нәни тел белән,
Җиңгәсенә килә ул.

— Елый күрмә, әй җиңгәй,
Тукта, зинһар, ташлачы!

Яулык белән күзең сөрт,
Кайгыларың каулачы!

---

Юмарт кияү Тохтаман
Киләткә һаман килә.
Көн дә, көн дә хатынын
Саламат белән кисә.

Мескен хатын чыдый шул
Газаплауга чарасыз,
Ахмак кияү белми тик,
Эшнең кая барасын.

Бер көн килде бер-берәү
Тилертергә ахмакны;
Нарспи чыгып киткәч тә,
Пыш-пыш нидер аңлатты.

Нарспи керде, кунакны
Сыра белән сыйларга.
Кунак китте, Тохтаман
Тагын килде кыйнарга.

— Һә, син шундый кыз икән!
Көлкегә калдыңмыни?
Сәтнәр белән, туй көнне
Урманга качтыңмыни?

Кыйный-кыйный Тохтаман,
Төрле газап китерә.
Хәзер халык теленнән
Байтак сүзләр сизелә.

Шулай, шулай, фәлән шул,
Андый эшләр җирдә күп.
Аулак төштә, ышыкларда
Начар эшләр бик тә күп.

Ата-ана үз кызын
Үстергәндә сөйсә дә,
Ләкин хатын булгачтын,
Явыз карт ир көнләшә.

Тотты бирде үз кызын,
Ата-ана бер байга.
Яратмагач бер-берен,
Ләкин аннан ни файда?

Тату, яхшы, килешеп,
Икәү бергә сайрашсаң;
Йөз кат артык бәхетле —
Фәкыйрь кеше байлардан.

Кыйна, кыйна, Тохтаман!
Җанын чыгар, җәлләмә!
Газапландыр, Тохтаман!
Эт ит, бетер, бәргәлә!

Кыйна, кыйна, Тохтаман!
Яшьләр шулай җайлансын!
Газапландыр Тохтаман!
Нарспи тизрәк картайсын!

Ләкин соңра, сиңа карт,
Үкенеч, кайгы төшмәсен.
Кыйна-кыйна Тохтаман!
Яшьләр синнән көлмәсен!

Үтеп китте өч атна,
Үтте симек, туй, рәхәт,
Һаман карт ир кыйнауга,
Нарспи түзде шул кадәр.

Ләкин айның ахырында,
Нурлы, матур бер кичтә...
(Тукта, хәзер сөйләмим,
Калып торсын бер читтә.)



## 10. НАРСПИ ХӘЛЕ

Кояш иртән тау менеп,
Күккә башын калкыта.
Җылы, юмарт нур белән
Дөнья йөзен балкыта.

Шул җәйге көн, матур көн,
Хушылка авылын нурлый.
Бар дөньяда тереклек,
Шатланып уйнап туймый.

Җибәрделәр жыр сузып
Дөм-дөм урманда кошлар.
Күгәрченнәр күк булып,
Төште чишмәгә кызлар.

Ләкин менә ак йортта
Бер тын да юк — шомлы чак.
Килен кеше ак йортта
Бер ялгыз ул — моңлы баш.

Иртән терлек ашаткач,
Китте кырга Тохтаман.
Бүген мескен хатынын
Кайгы тагын чолгаган.

— Хатын булдым ирексез,
Әткәй-әнкәй хур иткәч.
Ләкин мескен кызыгыз
Рәхәт күрми шул ирдән.

Кызганмыйча, мал итеп,
Җиде ятка саттыгыз.
Мин, кызыгыз, мескенне —
Янар утка салдыгыз.

Хәзер мескен кызыгыз,
Газап чигеп, сүнә бит.
Каһәр төшкән карт аны,
Эттән түбән күрә бит.

Ник соң, минем, сез шулай
Башым харап иттегез?
Сөйгән ярдан аерып,
Җаным һәлак иттегез?

Ник соң шунда, мин үзем,
Башым ашый алмадым?
Ник соң монда килергә —
Тәндә җаным асрадым?

Явыз белән бер өйдә
Ничек бергә торыйм соң?
Әллә башым бетеримме?
Ничек, ничек чыдыйм соң?

— Көчләп иргә бирделәр,
Газап, моңга салдылар,
Әткәй-әнкәй аңсызлар —
Миндә фәкать кайгы-зар.

Көчләп иргә бирделәр,
Рәхәт түгел көннәрем.
Әткәй-әнкәй аңсызлар —
Калды минем сөйгәнем.

Көчләп иргә бирделәр,
Исемем черде, чүп булды.

Әткәй-әнкәй аңсызлар —
Кайгы-газап күп булды.

Көчләп иргә бирделәр,
Минем гомер коллыкта.
Әткәй-әнкәй аңсызлар —
Нинди мәгънә тормышта?

Көчләп иргә бирделәр,
Газап-моңга салдылар.
Әткәй-әнкәй аңсызлар —
Миндә фәкать кайгы-зар...

— Ләкин минем сөйгәнем,
Йөрәк парам — гөлем бар.
Вәхши ирнең кулыннан
Килеп йолыр кешем бар.

Килерме икән сөйгәнем,
Урман сукмагы белән?
Үтерерме икән дошманны
Көчле куллары белән?

Юк, үз башым беткәнче,
Дошманымны юк итәм...
Газап күреп түзгәнче,
Тохтаманны... юк итәм.

Ләкин көчем җитәрме?
Качып китеп булырмы?
Әй син, көчле Пулехче!
Җаным тетри, булышчы!

Ләкин көчем җитәрме?
Ничек качып котылыйм?
Әй, бер аллам, булышчы,
Кайда барып тотыныйм?

Бетсәң, тизрәк бет, дошман!
Минем тормыш эттән ким!
Бүген әйдә, наргымыш [1]
Белгән эшең эшләп бир!

---

[1] Наргымыш — үтергеч агу — мышьяк.

Шулай бүген йортында
Нарспи, мескен сукрана.
Җаны тетри өзлексез,
Усал уйлар кузгала.

---

Ут күк кояш уйнаклап,
Үрләп бара түбәгә.
Акрын-акрын төш җитә,
Кыска кала күләгә.

Тышта дөнья җемелди,
Тышта дөнья шат карый.
Нарспи елый бүлмәдә,
Бәгърен кайгы-зар талый.

Сәнтти килде атланып,
Көянтәсен сикертеп,
Җиңгәсенең каршына
Керел китте җимертеп.

Кыйный батыр, атчыгын,
Чыбык белән — шак та шык.
Белми-күрми җиңгәсен
Китә язды таптатып.

Ләкин ул да җиңгәсен
Бүген аңлый алмады.
Атын алып, аптырап,
Өйдән тышка атлады.

---

Матур килен, кич-кырын
Салма бутый ашыгып,
Учак яна, елан күк
Пыш-пыш килә атылып.

Матур килен, кич-кырын
Салма бутый, пешерә.
Сөйли шунда бер тоташ,
Өрә-өрә төкерә.

„Җитмеш диңгез ягыннан,
Килче, карчык Шаппатан!
Өр дә төкер салмага,
Бетсен усал Тохтаман!

Алтмыш диңгез артында
Уйный, сикерә җиз бүкән.
Сикер, сикер, катырак!
Китсен усал йөз түбән!

Утыз да бер тауларда,
Җиз казанда, салма, пеш!
Шул салмада пеш, елан!
Син, тамукка бар да төш!“.

Нарспи-килен йортында
Тәмле салма пешерә.
Сөйли шулай бер тоташ,
Өрә-өрә төкерә...

Нарспи-килен йортында
Салма бутый ашыгып.
Үлем ашы — елан күк,
Чыж-чыж пешә атылып...

---

Кич тә булды, Тохтаман
Кырдан әйләнеп кайта.
Утыра булар чыгарып,
Өстәл өстендә салма.

Кашык алып Тохтаман
Керде өстәл артына.
— Салма бүген тәмле, дип,
Мактый шунда аз гына.

Ямьсез күзен боргалап,
Йодрык кысып җикеренә:
— Салма тәмле, кил монда,
Торма, ахмак, кил менә!

— Юк, юк, килми ашыйсым,
Өлгерермен ахырдан...

Ах, Нарспи, түзмичә,
Чыгып китте яныннан.

Тышта тора яшь хатын
Яшен җиргә агызып.
Карты ашый салмасын,
Әфен-төфен ашыгып.

---

Тыгын, тыгын, Тохтаман,
Наргымышлы салманы!
Хәзер синең Нарспига
Ирлек көнең калмады!

Беттең инде, Тохтаман!
Сүнде дөньяң, бездән кал!
— Нарспи, тизрәк өйгә кер,
Йокым килә, мендәр сал!

„Менә, ходай, нишләдем,
Эчтә тамук бар кебек.
Су да эчтем туйганчы,
Сыра эчкән чак кебек“.

Нарспи керә шушында,
Карты җирдә аунала.
Бөтен эчен, бавырын,
Зәһәр салма актара.

Нарспи урынын җәйде дә,
Картын түшәккә салды.
Тотып-тотып бәрде дә,
Җан китте дә, тән калды.

Бетте бер җан дөньяда
Вәхшилеккә чик җитте.
Бетте ерткыч гомергә,
Йөрәк тынды, тир кипте.

Өйдә өстәл, бүкәннәр
Куркыталар хатынны.
Көтә килен тын гына
Караңгырак вакытны.

Өйдә өстәл, бүкәннәр
Бары да тып-тын булдылар.
Күреп хуҗа гәүдәсен,
Кызганышып куйдылар.

Менә, иркен җир йөзен,
Караңгылык каплады.
Төнге тынлык Нарспины
Куркындыра башлады.

Бетте карты гомергә,
Хәзер торып китмәс ул.
Ач ат, сыер, сарыкка
Чыгып азык бирмәс ул.

Менә атлар ачлыктан,
Кешнәшәләр абзарда.
Ләкин сезне, үксезләр,
Хуҗа юк шул аңларга!

---

Авыл чите — дөм урман,
Яфрак, ботак дерелди.
Мең-мең йолдыз уйнаклап
Иркен күктә җемелди.

Хушылкада чувашлар
Йоклый бары да хырылдап.
Очты бакча өстеннән
Тик бер кошчык пырылдап.

Айның сырты тәгәрәп
Чыкты урман сыртыннан.
Атлый-атлый тын гына,
Чыкты Нарспи, йортыннан.

Китте шәүлә күк шуып,
Бакча, ындыр артына.
Китте чыгып авылдан,
Чапты урман авызына.

Бер күрим, дип, омтылып,
Ай да чапты күп вакыт.

Урман калды иңрәнеп,
Нарспи узгач күз салып.

---

Нарспи бара урманнан,
Никтер артык ярсынып,
Тып-тын тора дөм урман,
Нарспи җанын яндырып.

Карт агачлар бөгелеп
Җанга курку салалар.
Нарспи чабып үткәндә,
Киң юл биреп калалар.

Карт агачлар төбендә,
Шүрәлеләр уйныйлар.
Нарспи чабып үткәндә,
Кул сузарга уйлыйлар.

Көтмәгәндә җил чыгып
Дулап китте дөм урман.
— „Тот, хатының, Тохтаман!
Кичегерсең төн узгач!

Тот хатының, Тохтаман!
Нинди усал хатын бит!“
... Утыз да бер шайтанча —
Урман күкри, давыл-җил...

---

Иртән торып киенгәч,
Сәнтти тышка атылды.
Көянтәсен атланып,
Җиңгәсенә ашыкты.

Ләкин җиңгә күренми,
Абзый һаман да йоклый.
Сәнтти шунда аптырый,
Селкеп куйса да тормый.

Берәү килеп керде дә,
Катып китте онытылып,
Карап торды, торды да,
Чабып чыкты омтылып.

Азрак вакыт үткәч тә
Халык тулды өй алга.
— „Ничек үлгән Тохтаман?
Нарспи-килен, син кайда?“

Ләкин күпме сорап та,
Әзгә баса алмассыз!
Салкын мәет сөйләмәс —
Җавап таба алмассыз!

Ләкин күпме сорап та,
Ни дә кора алмассыз!
Нарспи йөри урманда,
Мәңге тота алмассыз!





## 11. СИЛБИДӘ

Олы Силби авылында
Төн үтә дә көн туа.
Акрын-акрын гомерләр
Һаман шуа да шуа.

Олы Силби авылында
Уза көннәр каулашып,
Үтеп киткән симекнең
Шатлыгына шатланып.

Чуваш киндер киенә,
Кырның өсте күк төсле.
Җырлый-җырлый эшли ул,
Үгез кебек — нык, көчле.

Тора иртән таңда ук,
Иртән кырга бара ул.
Ялт-йолт ашын ашый да,
Иңгә чалгы сала ул.

Болынлыкта кибәннәр,
Чүмәләләр калалар.
Печән үткәч, чувашлар
Иркен кырга баралар.

Үткен чалгы чыж килә,
Соңга калган чалуда.
Башлы арыш саргая,
Иксез-чиксез басуда.

---

Төрле сүз күп авылда,
Йомшак телләр очынла,
Дөресләр дә бардыр шул,
Шул хәбәрләр эчендә.

Силбидә дә адәмнәр,
Нарспи, Тохтаман, диләр.
Алар күптән кияүнең
Усаллыгын сөйлиләр.

Михәдәрдән шикләнеп,
Сүзләр йөри авылда,
Башны кашып, кызганып,
Аптырыйлар бары да.

Озакламый ул сүзләр
Сәтнәргә килеп җитә.
Әнкәсеннән аерылып,
Ялгыз урманга китә.

Кырда эшли кешеләр,
Кичен өйгә китәләр.
Кичке ашлар алдында,
Нарспи да Сәтнәр, диләр.

---

Сәтнәр атлый бер ялгыз,
Урманнан алга таба.
Нарспи кайгысын уйлап,
Дошманга яный бара.

— Шәфәкъ батар, кич булыр
Хушылкага җиткәнче!
Дошман җаны тын булыр,
Кояш нурын сипкәнче!

Кояш чыгар, яктыртыр,
Халык торыр барысы да,
Ләкин дошман селкенмәс,
Йокы артык татлыга.

Кояш чыгар яктыртыр,
Һәм мин тагын урманга...
Ләкин дошман кузгалмас,
Нарспи калмас урынында!

...Ләкин Нарспи ансыз да,
Чыкты кичен йортыннан,
Сәтнәр килеп житкәнче
Качты ерткыч дошманнан.



## 12. УРМАНДА

Шаулый, гөжли дөм урман,
Очсыз-чиксез һәм көчле...
Кулсыз-башсыз җил чыккан,
Мәңге туктамас төсле...

Шаулый-гөжли дөм урман,
Тамукта янган чаклы.
Шүрәле күк, шайтан күк
Котырына җилгә каршы.

Вакыт-вакыт җил килә,
Выж-выж дулап, кысылып...
Кара урман гөрелди,
Җиргә кадәр сыгылып...

Кара болыт өзлексез,
Килә урман артыннан.
Яшен бәрә җир ярып,
Кара болыт астыннан.

Яшен бәрә, шартлата,
Бөтен дөнья дөр килә.
Чиләк-чиләк яңгырдан,
Чокыр-чакыр гөр килә.

Дөм-дөм урман, дөм урман,
Ник соң болай шаулыйсың?
Ник соң выж-выж сызгырып,
Наратларың чайкыйсың?

Дөм-дөм урман, дөм урман,
Ник соң тыныч тормыйсың?
Ник соң минем җанымны
Куркытасың, борчыйсың?

Урман тагын катырак
Шаулый, елый тулгана.
Тугрым, кичер! ташлама!
Ахыр заман кузгала!

Аһ, гөнаһлы башымны,
Кайда илтеп салыйм соң?
Аһ, гөнаһлы җанымны,
Ничек йолып калыйм соң?

Бүген Сәтнәр, мескенем,
Азгын, шашкын урманда.
Җырлый анда наратлар,
Гөрләп давыл узганда.

Кысан, тыгыз сукмакта,
Йөрәк янгынын кушып,
Урман шавын күмгәндәй,
Атлый Сәтнәр җыр сызып.

— Дөм-дөм урман, дөм урман,
Ник соң болай шаулыйсың?
Ник соң выж-выж сызгырып,
Наратларың чайкыйсың?

Дөм-дөм урман, дөм урман,
Ник соң тыныч тормыйсың?
Ник соң мескен җанымны,
Куркытасың, борчыйсың?

Ах син, кайгым, тыңлачы!
Ник соң уттай кабасың?

Ник соң минем, үксезнең,
Шатлыкларын басасың?

Тудым газиз әнкәмнән,
Ким-хур, газапка тудым,
Шул сагыштан, кайгыдан,
Яшь башым һәлак булыр...

Башым һәлак булыр ла,
Малым юклык — шул изде.
Ул да берни түгел дә,
Ахмак җаннар хур итте.

Ахмак җаннар бер бәла,
Усал дошман тап булды.
Усал дошман чүп кенә,
Ходай язган — хак булды.

---

Сәтнәр жырлый җырларын,
Көчле давыл киләдер.
Сәтнәр моңын гөрләтеп
Елап, шаулап китәдер.

Шул кайгылы тавышлар,
Җан, йөрәкне тырныйлар.
Агып көчле җил белән,
Ерак-ерак чыңлыйлар.

Алар кара урманга
Акрын-акрын сеңәләр.
Шушы яшьле авазлар,
Бер яшь җанга керәләр.

Ерактарак, кайдадыр,
Кем соң тагын зар елый?
Усал газап, кайгыдан
Анда башка җан елый.

Серле җырның моңнарын
Сәтнәр ашкынып тыңлый.

Көчле давыл-җил белән,
Сәтнәр кайгылы җырлый.

— Кара урман, дөм урман,
Ник соң көчле шаулыйсың?
Сөйгән кызым җырына
Охшаш җырга каплыйсың?

Кара урман, дөм урман,
Ник соң башың селкәсең?
Үлгән җаным уятып,
Тагын өмет кертәсең?

Зур-зур урман, зур урман,
Гөрли-гөрли аглама!
Зинһар, минем, үксезнең,
Йөрәк хисен алдама!

Зур-зур урман, зур урман,
Горур башың болгама!
Дустым җырын китереп
Газап-моңга чолгама!

Шаулы урман, киң урман,
Әйтче чынын, килсәнә!
Мескен җанны кызганып,
Сөйгән кызны бирсәнә!

Тукта! Минем алдыма,
Килә... килә бер чибәр!
Олуг тугры! ярлыка!
Нарспи, Нарспи, син микән?

---

Ике гашыйк кавышкач,
Иде башын зур чыршы.
Берәр кабат җил узгач,
Тирән урман шып тынды.

Җилләр урман артына,
Болытларны каулады.

Кояш балкый түбәдә,
Кошлар сайрый башлады.

Чирәмнәрдә чыкларга
Кояш бирә яктысын,
Ике яшь җан-гашыйкка,
Кояш бирә ялкынын.

Балкый матур яңа көн,
Хәзер урман шавы юк.
Явыз көннең эше юк,
Явыз көннең хакы юк!

Сөешеп атлый ике җан,
Хәзер йөрәк давы юк.
Җиде ятның эше юк,
Җиде ятның хакы юк!

Чиный ләкин кара кош,
Урман моңын бозгалап...
Нарспи җанын эзлидер,
Ай Тохтаман! Тохтаман!



## 13. А Т А-А Н А

Кеп-кечкенә бер өйдә,
Икәү алар — килде аш.
Тәп-тәбәнәк өстәлдә,
Ашый алар кичке аш.

Кап-карт, Сәтнәр әнкәсе —
Күршедән катык тапты.
Икмәк, тозын чыгарып
Өстәл өстенә салды.

Ризыклана ике җан
Кайнар сүзләр балкытып,
Мескен, Сәтнәр әнкәсе
Тыңлап тора кайгырып.

Сагыналар үткәнне —
Матур, тыныч чакларны,
Кичке аулак, шау-шуны,
Симеккәчә таңнарны.

Кинәт кенә куркытып,
Китте ишек ачылып.
Михәдәр дә, карчык та
Килде, керде ашыгып.

Карчык

Безнең Нарспи бу йортта
Юк микән, дип кердек без.
Сизгер күзләр сүзеннән
Шушында, дип белдек без.

Михәдәр

Әх, кыз, кы-ыз, кызмы син!
Нарспи, нәрсә кылдың син?
Ничек халык каршында,
Хурлыкларга тыктың син!

Ни җитмәгән соң сиңа?
Ни җитмәгән, акыллым?
Ник бер нигә карамый —
Сәтнәр-эткә ягылдың?

Бай кыз булган башыңнан,
Ник соң болай тилердең?
Мәңге хурлык күрмәдем —
Ләкин хәзер китердең!

Карчык

Ни җитмәгән, ахмакка,
Ир үтереп качарга?
Сәтнәр белән урманда,
Лаштыр-лыштыр чабарга?

Михәдәр

Шөкер-шөкер, ходайга!
Начар исемем булмады.
Хәзергәчә пәри дә,
Кирәмәт тә сукмады.

Минем йортым, җиремә,
Изге фәрештә бакты.
Шуңа күрә авылда
Исемем мактауда калды.

Пүлех, харпан, нур-дөнья
Мине сыйпап килделәр,
Кывак хуппи[1], нур-кояш
Миңа табыш бирделәр.

Мин шул көнгә життем дә,
Башым түбән идердең.
Матур көнем бозылды —
Син шул хәлгә китердең.

Карчык

Орыш ыграк, тет, хужам,
Сәтнәр-этнең тетмәсен!
Эштә каткан кул белән,
Бай кызларын белмәсен.

Михәдәр

Мин нәнидән үстердем,
Кыз күңелен тыймадым.
Сөйгән кызым булганга,
Көн-төн байлык жыйнадым.

Көн-төн эшләп, түшәктә
Тыныч йоклап ятмадым.
Кызым өчен тырышып,
Һичбер күзем япмадым.

Ничек бирим иргә, дип,
Уйлый-уйлый эшләдем.
Сөйгән кызым бәхетенә,
Баерак кияү эзләдем.

Кияү таптым, туй иттем,
Менә бүген ни килде!
Минем газиз башкайга,
Менә бүген ни житте!

Карчык

Орыш, орыш, кызганма,
Йөзе кара баланы!

---
[1] Кывак хуппи — күк кабагы ачылу.

Син кем кызы булдың соң?
Кем соң сине карады?

Михәдәр

Мин нәнидән үстердем,
Йөзен күреп, сөенеп,
Шул вакытка җиттем дә,
Башым бетте көенеп.

Шул вакытка җиттем дә,
Кызым башны ашады.
Кайгырмыйлар ул кызлар,
Янсын, көйсен атасы...

Әткәң, әнкәң ирке бит
Булды сиңа шәфкатьле.
Сәтнәр өчен койдырдың,
Безнең ап-ак чәчләрне.

Сүз дә, эш тә, байлык та,
Булышмады азрак та.
Шундый бай ир бар чакта,
Булмас болай ахмак та!

Нарспи

Әй әткәем, әткәем!
Ул тормыш бит — җәһәннәм;
Җан сөймәгән кияүгә
Һич булмагач мәхәббәт.

Әй әткәем, әткәем!
Яхшы тормыш кайда ул? —
Түгел байлык эчендә —
Җанга якын җанда ул.

Карчык

Ай-ай усал, бик артык
Ерма инде авызыңны!

Анаң эчен яндыртып,
Әллә үчең алдыңмы?

Михәдәр

Ай, зур хурлык китердең!
Хәзер гайбәт сөйләрләр...
Кызың фәлән-төгән дип,
Миңа бармак төртерләр.

Ләкин төрле авызлар,
Кирәк-ничек җенләнсен,
Исемең черек булса да,
Син минем кыз бердәнбер.

Әйдә, кызым, бу өйдән,
Ишелеп төшмәс борын!
Тагын кияү табарбыз,
Исемең черемәс борын!

Әйдә, кызым, кайгырма,
Синең әткәң бар әле!
Исемең черек булса да,
Әткәң маллы, бай әле!

Карчык

Әйдә, көчек, кызурак!
Миңа бер дә карамый!
Сәтнәр-көчек, киез бит,
Бай кызларын чамалый.

Нарспи

Әй әткәем, әткәем!
Нигә эчем тырныйсың?
Исемем черек көенчә,
Нигә өйгә кыстыйсың?

Карчык

Күрче, тагын ни әйтә
Сөйгән кызың, ныграк бак!

Михәдәр

Карчык, җитәр, укынма,
Кызың сүзен тыңлап бак!

Нарспи

Хатын булгач кабаттан,
Өйгә кайтып китимме?
Явыз ирдән котылгач,
Тагын газап чигимме?

Юк, юк, әткәй, дәшмә дә,
Хәзер өйгә басмамын!
Шушы килеш үлсәм дә,
Кияү көтеп ятмамын!

Үстердегез, сез, әткәй,
Сабый чакта сөйдегез,
Ләкин буйга җиткәч тә,
Җаным белми йөрдегез.

Мин бит сезгә баш ордым,
Мин бит сезгә аңлаттым.
Чиккә җитә башлагач,
Җиргә ятып ялвардым.

Үстердегез сез, әткәй,
Үстердегез, бактыгыз.
Ләкин үскәч юк булдым,
Акча өчен саттыгыз!

Сабый чакта сез миңа,
„Бәбкәм“ дигән булдыгыз.
Нәрсә сорый кызыгыз —
Шуның барын куйдыгыз.

Үскәч, башта, әткәйгә,
„Бер ел көт“ дип сөйләдем.
Әткәй орышып бетерде,
Син дә чәчтән сөйрәдең!

Ник соң минем күңелгә
Соңгы кабат кермәдең?
Әткәй, әткәй, без болай
Булмый идек, белмәдең!..

Әткәй, ялгыз кызыңны
Ник бирдең соң бүрегә?
Сиңа рәхәт булып шул
Акча гына күренә.

Шундый авыр хурлыкка,
Үзең сәбәп, без түгел.
Сәтнәр белән булмасам —
Атам, анам — сез түгел!

Әй әткәем, әнкәем,
Сәтнәр ирем — сүзем бер.
Безне бәхил итегез,
Бергә рәхәт күрербез!

Карчык

Күр, күр, явыз ни сөйли,
Сәтнәр сәбәп барына.
Киттек әйдә, Михәдәр,
Төкер кызың башына!

Михәдәр

Әх, син, Сәтнәр, Нарспины
Харап иттең бит, шайтан!
Ә син усал җүләр кыз,
Кара йортта кип, саргай.

Менә, тукта, йортыма
Үзең чабып килерсең.
Шунда минем нихәтле
Гаделлегем белерсең!

Әйдә, киттек, карчыгым,
Түзмәс, кайтыр кыш белән,
Инде тәмам сүз бетте,
Безнең бүген кыз белән.

## Карчык

Коры яфрак шикелле,
Кибеп, шиңеп, бетегез!
Этчә газап күрегез!
Шунда тәмам черегез!

---

Орышып, сүгеп чыктылар
Болар тышка тиз генә.
Урам буйлап карчыгың
Усал сүзләр сиптерә.

Кояш никтер оялган,
Кызарып, елап батты.
Аһ, дип, Сәтнәр әнкәсе
Өстәлгә башын салды.



## 14. ДҮРТҮЛЕМ

Авыр эшләр соңыннан
Йокы нидән дә татлы.
Силби авылының халкы
Тирән йокыга талды.

Йоклый бөтен адәмнәр,
Кара урман тик тора.
Вакыт-вакыт җил генә
Урман тынлыгын боза.

Килеп чыкты урманнан
Менә ике шәп арба.
Авыл буйлап тын гына
Китеп барды пар ат та.

Менә тавыш ишетелә,
Килә дә җанга каба.
Менә тавыш ишетеп,
Берәү урамда чаба.

Шылдыр-шылдыр арбалар
Бии-бии юл алды.
Урман якка тәгәрәп
Кереп китте, югалды.

Бөтен урам гөр килә,
Әллә нинди бер гауга,
Халык шаулый урамда,
Чаба да чаба бары да.

— Михәдәрнең йорт-җирен
Талаганнар, мин беләм!
Чаба-чаба шулай дип,
Кычкыргалый бер берәү.

Бары да Тури-гаскача
Чатыр-чотыр чабалар.
Ни булды да, ни булды?
— Сораштырып баралар.

— Михәдәрнең йорт-җирен
Талаганнар, басканнар!
Бер нием дә калдырмый,
Алганнар да качканнар.

Җир йоткыры караклар,
Зур бозыклык кылганнар.
Алладан да курыкмый,
Гөнаһ эшләп шылганнар.

Михәдәрне, карчыкны
Икәвен дә суйганнар.
Җиде ялчы-йолчыны,
Исерек ясап куйганнар.

Бу тавышны ишетеп,
Сәтнәр йөгереп барган.
Балта белән бер карак,
Шунда маңгаен ярган.

Михәдәрне үтереп,
Малын-милкен алганнар.
Алладан да курыкмый,
Аңсыз, башсыз ахмаклар.

Бетте мескен Сәтнәр дә,
Канлы үткен балтадан.

Силби авылы кайчан да,
Мондый хәлгә калмаган.

Михәдәрнең Нарспие
Күз яшен дә белдерми.
Әткәсенең йортында
Урыныннан да селкенми.

Тирмән ташы дыр да дыр,
Йөрәк өстен кимерә.
Тирмән ташы астында,
Мескен йөрәк киселә.

Аһ, киселеп китте дә,
Нарспи ауды да китте.
Тагын аңга килде дә,
Үкереп елап яшь түкте.

Әй син әткәй, син әнкәй!
Ник соң мине таптыгыз?
Якты дөнья өстендә,
Кайгы-моңга салдыгыз!

— Әй бер аллам, кадирым,
Җан биреп тә, чикләдең!
Мескен яшь-яшь башыма
Бер бәхет тә бирмәдең?

Әй җанкаем — яшь башым!
Ник соң болай булдың син?
Бөтен дөнья каршында
Булдың артык, булдың ким!

Елый-елый кайгырып,
Нарспи чыкты авылдан,
Кырга чыкты да китте,
Киндер, җитен ягыннан.

Авыл халкы, артыннан
Кызганып карап калды.
Шушы хәлләр турында
Сөйләнде төнгә чаклы.

Икенче көн иртәсен
Чуваш кырга бармады.
Атна көне булганга
Һич эшкә кул салмады.

Әлекке күк, урамга
Гүзәл кызлар чыкмады,
Уйнарга да биергә
Егетләр дә кыймады.

Төрле җирдә карт-коры
Төркем-төркем торалар,
Михәдәрнең йорт-җирен
Сатарга уй коралар.

Нарспи кайда икән, дип,
Эзләр өчен киттеләр.
Михәдәрне, карчыкны
Күмәр өчен килделәр.

Ай, нинди зур каберлек!
Өч үлек жан, өч менә...
Чибәр егет Сәтнәр дә
Имән төбендә генә.

Бөтен авыл, төш аугач,
Бот чаба да, шакката.
Нарспи гәүдәсен табып,
Берни белми баш вата.

Эзләгәннәр кайттылар,
Чапкыннарын яндырып.
Билбау тагып карт талга,
Үлгән, диләр, асылынып.

Шунда, үлгән урынына,
Күмеп куйдылар аны.
Чыбык читән тирәләп,
Тотылды бөтен ягы.

Кояш батты, кич булды.
Чуваш йокыга тала.

Кояш чыкты, көн булды,
Чуваш басуга бара.

Ләкин безнең Нарспига
Мәңгелеккә кич булды.
Гомер — тыгыз кабердә,
Кайгы-зарга чик булды.

Шулай булды яшь гомер,
Тәмам булды яшь килеш,
Әткә, әнкә башсызга,
Кайгы-хәсрәттә кибеп.

Күрде якты җир йөзен
Алла җанын иңдергәч,
Буйга җитте, кыз булды,
Әткә, әнкә үстергәч.

Олуг тугры күңеле
Кызны аңлы ясады.
Әткә, әнкә нәфесе
Аның башын ашады.

Ятты кысан кабергә,
Исеме калды авылга.
Аның моңлы җырлары,
Тора халык аңында.

Һаман, һаман Силбидә
Җырлыйлар моңлы җырны,
Хәтерлиләр сагынып,
Мескен бәхетсез кызны.

Һаман, һаман Силбидә
Каберлеккә киләләр.
Яңгыр яумый торганда,
Сулар сибеп китәләр.

# ЭЧЕНДӘ


| | Бит |
|---|---|
| Кереш | 3 |
| 1. Силби авылында | 9 |
| 2. Гүзәл кыз | 15 |
| 3. Симек киче | 22 |
| 4. Туй | 30 |
| 5. Багучы янында | 34 |
| 6. Качу | 38 |
| 7. Ике туй | 43 |
| 8. Хушылкада | 48 |
| 9. Симек үткәч | 54 |
| 10. Нарспи хәле | 58 |
| 11. Силбидә | 67 |
| 12. Урманда | 70 |
| 13. Ата-ана | 75 |
| 14. Дүрт үлем | 83 |


---


*К. ИВАНОВ*

НАРСПИ

(на татарском языке)

Җаваплы редактор *С. Урайский*

Басарга кул куелды 1/IX-41 ел. Тираж 3070. Басма табак 5½. Табакта 44000 хәреф. Авт. 3,47 табак. Заказ № 129. П.Ф № 4710. Бәясе 2 сум 20 тиен. Төпләү 1 сум 50 тиен.

Басылды Камиль Якуб исемендәге китап фабрикасында. Казан, Бауман, 19. 1941 ел.